**ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ЗАКУПКАМ**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ САТЫП АЛУЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

24.05.2023 № 09-07-02

Казан шәһәре

Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитетының 2018 нче елның 29 нчы июнендә язылган 09-05-102 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазифасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс үткәрү турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

2004 нче елның 27 нче июлендә кабул ителгән 79-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» Федераль закон, Россия Федерациясе Президентының 2005 нче елның 1 нчы февралендә чыгарылган 112 номерлы «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазифасын биләүгә конкурс турында» Указы, 2023 нче елның 26 нчы гыйнварында кабул ителгән 1-ЗРТ номерлы «Татарстан Республикасының Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Президентының 2023 нче елның 4 нче февралендә чыгарылган УП-68 номерлы «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе) Администрациясе турында» Указының 4 нче пункты нигезендә б о е р ы к б и р ә м:

Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитетының 2018 нче елның 29 нчы июнендә язылган 09-05-102 номерлы «Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазифасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс үткәрү турында Нигезләмәне раслау турында» (2021 нче елның 25 нче февралендә 04-05-24 номерлы боерык белән кертелгән үзгәрешләр белән) боерыгы белән расланган, Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазифасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс үткәрү турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.2. нче пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Конкурс граждан хезмәтенең вакантлы вазифасын биләү өчен кандидатларның һөнәри дәрәҗәсен бәяләүдән, аларның бу вазифаны биләү өчен билгеләнгән башка квалификация таләпләренә туры килүен тикшерүдән һәм граждан хезмәте вазифасына билгеләү өчен кандидатлар арасыннан гражданинны (граждан хезмәткәрен) шундый бәяләү һәм тикшерү нәтиҗәләре буенча сайлап алудан гыйбарәт»;

түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

«Конкурс барышында кандидатларның һөнәри дәрәҗәләре чагыштырыла, аларның һөнәри белем дәрәҗәләре, граждан хезмәте стажы яки белгечлеге, әзерлек юнәлеше буенча эшләве, шулай ук аларның белгечлекләре, әзерлек юнәлешләре (белгечлекләр һәм әзерлек юнәлешләре зурайтылган төркемнәре), һөнәри яктан яңадан әзерләү буенча өстәмә һөнәри программаларны үзләштерү нәтиҗәсендә алынган квалификацияләре (граждан хезмәтенең вакантлы вазифасын биләү өчен квалификация таләпләре белән мондый таләпләр каралган очракта) чагыштырыла».

1.5 нче пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«граждан хезмәте вазифаларының кече төркеменә караган граждан хезмәте вазифаларына билгеләгәндә, шулай ук федераль законнарда каралган башка очракларда, эшкә алучының вәкиле карары буенча»;

2.4 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.4. Конкурс комиссиясе составына Дәүләт комитеты рәисе һәм (яисә) аның тарафыннан вәкаләтләр бирелгән граждан хезмәткәрләре (шул исәптән дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазифасын биләүгә конкурс үткәрелә торган Дәүләт комитетының кадрлар бүлеге эшләрен алып бару һәм структур бүлекчәсе өчен җаваплы хезмәткәре), Дәүләт комитеты карамагындагы Иҗтимагый совет вәкилләре, шулай ук бәйсез экспертлар – Дәүләт комитеты рәисенең бәйсез белгечләрнең шәхси мәгълүматларын күрсәтмичә соравы буенча Татарстан Республикасы Рәисе карамагындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты тарафыннан законнарда билгеләнгән тәртиптә чакырылучы кадрлар технологияләре һәм граждан хезмәте мәсьәләләре буенча тиешле өлкәләрдә һәм һөнәри хезмәт эшчәнлегенең төрләрендә белгечләр булган фәнни, белем бирү һәм башка оешма вәкилләре керә.

Бәйсез экспертның конкурс комиссиясендә гомуми булу вакыты өч елдан артмаска тиеш. Әлеге вакыт бәйсез эксперт конкурс комиссиясе составына беренче тапкыр кертелгәннән алып исәпләнә. Бу бәйсез экспертны конкурс комиссиясе составына яңадан кертү аның конкурс комиссиясендә тору вакыты беткәч өч елдан сон гына башкарылырга мөмкин.

Дәүләт комитеты карамагындагы Иҗтимагый совет вәкилләренең һәм бәйсез экспертларның гомуми саны конкурс комиссиясе әгъзаларының гомуми саныннан кимендә дүрттән бер өлешен тәшкил итә.

Дәүләт комитеты рәисе соравы буенча конкурс комиссиясе составына кертелүче Дәүләт комитеты карамагындагы Иҗтимагый совет вәкилләре, Дәүләт

Комитеты карамагындагы тиешле Иҗтимагый совет карары нигезендә билгеләнәләр»;

3.2. нче пуктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гражданинга (граждан хезмәткәренә) түбәндәге очракларда конкурста катнашырга рөхсәт ителми:

а) аның һөнәри белем дәрәҗәсе, граждан хезмәте стажы яки белгечлек буенча эш стажы, әзерлек юнәлеше өлкәсендәге квалификация таләпләренә туры килмәве сәбәпле;

б) аның белгечлек, әзерлек юнәлеше (белгечлекләрнең һәм әзерлек юнәлешләренең зурайтылган төркемнәре), һөнәри яктан яңадан әзерләү буенча өстәмә һөнәри программаларны үзләштерү нәтиҗәсендә алынган квалификация (граждан хезмәтенең вакантлы вазифасын биләү өчен квалификация таләпләре белән мондый таләпләр каралган очракта) таләпләренә туры килмәве сәбәпле;

в) граждан хезмәтенә керү һәм аны узу белән бәйле һәм Россия Федерациясенең дәүләт граждан хезмәте турындагы законнары белән билгеләнгән чикләүләр белән бәйле;

3.4 нче пунктның «г» пунктчасының өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«нотариус яисә хезмәт итү (эш) урынында кадрлар хезмәте раслаган белем һәм (яисә) квалификация турындагы документларның күчермәләре, шулай ук гражданинның теләге буенча гыйльми дәрәҗә, гыйльми исем бирү турындагы документларның күчермәләре»;

4.1 нче пунктта «һөнәри һәм шәхси сыйфатлар» дигән сүзләрне «һөнәри дәрәҗә, һөнәри һәм шәхси сыйфатлар» дигән сүзләр белән алмаштырырга;

4.2 нче пунктта «бәяләү» сүзе алдыннан «һөнәри дәрәҗәне» дигән сүзләр белән тулыландырырга;

4.4.1 нче пунктның 15 нче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«гражданинның (дәүләт хезмәткәренең) һөнәри белем дәрәҗәсенә, һөнәри хезмәт стажына яки белгечлек буенча эш стажына, әзерлек юнәлешенә, һөнәри дәрәҗәгә, шулай ук Министрның тиешле карары булган очракта, белгечлеккә, әзерлек юнәлешенә (белгечлекләрнең һәм әзерлек юнәлешләренең зурайтылган төркемнәренә), һөнәри яктан яңадан әзерләү буенча өстәмә һөнәри программаларны үзләштерү нәтиҗәсендә алынган квалификациягә туры килүен тикшерү».

4.4.8 нче пунктның икенче абзацын «конкурс комиссиясе тарафыннан бәяләү» дигән сүзләр алдыннан «һөнәри дәрәҗәне» дигән сүзләр белән тулыландырырга;

4.4.9 нчы пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Конкурс үткәргәндә конкурс комиссиясе кандидатларны белем һәм (яисә) квалификация, граждан яки башка дәүләт хезмәте үтү, башка хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыру турындагы документлар нигезендә, шулай ук федераль законнарга һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларына каршы килмәгән кандидатларның һөнәри дәрәҗәсен, һөнәри һәм шәхси сыйфатларын бәяләү ысулларын кулланып, конкурс процедуралары нигезендә, шул исәптән граждан хезмәтенең вакантлы вазифасы буенча эш бурычларын үтәүгә бәйле мәсьәләләр

буенча индивидуаль әңгәмә, анкета үткәрү, төркемнәрдә дискуссияләр уздыру, реферат язу яисә тест үткәрү нигезендә бәяли»;

4.4.10. нчы пунктта:

беренче абзацта «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы дәүләт хезмәте һәм кадрлар Департаменты тарафыннан» дигән сүзләрне «Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы дәүләт хезмәте һәм кадрлар Департаменты тарафыннан» дигән сүзләр белән алмаштырырга;

өченче абзацта «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы дәүләт хезмәте һәм кадрлар Департаменты тарафыннан» дигән сүзләрне «Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы дәүләт хезмәте һәм кадрлар Департаменты тарафыннан» дигән сүзләр белән алмаштырырга;

4.4.12 нче пунктның икенче абзацын «комиссия бәяли» сүзләре алдыннан «һөнәри дәрәҗәне» сүзләре белән тулыландырырга;

4.8 нче пунктның беренче абзацын «граждан хезмәтенең, әмма» дигән сүзләрдән соң «һөнәри дәрәҗә» сүзләре белән тулыландырырга;

2. Әлеге боерык 2023 нче елның 29 нчы апреленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитеты рәисе урынбасары И.Г. Багаутдиновка йөкләргә.

Рәис Р.Н.Сабиров